**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 август № 547

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республи-касының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты көнкүреш калдыкларын туплау нормативларын билгеләү турында» 2016 ел, 4 апрель, 269 нчы карарын, Татарстан Республикасы Экология кодексын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 бүлегендә:

4.2.11 пунктның җиденче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.12 пунктның өченче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.13 пунктның унберенче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

4.8 бүлегендә:

«Каты көнкүреш калдыкларын урнаштыру һәм зарарсызландыру объектлары» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Каты коммуналь калдыкларны урнаштыру һәм зарарсызландыру объектлары»;

4.8.57 пунктта:

беренче абзацта «каты көнкүреш калдыклары (алга таба – ККК)» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар (алга таба – ККК)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «ККК» сүзен «ККК» сүзенә алмаштырырга;

4.8.58, 4.8.60, 4.8.61, 4.8.62, 4.8.65, 4.8.67, 4.8.69 пунктларда «ККК» сүзен «ККК» сүзенә алмаштырырга;

5.3 бүлектә:

5.3.65 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3.65. Шәһәр төзелешен проектлаштырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирлекләрнең яки шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (Татарстан Республикасы законы нигезендә вәкаләтләр бирелгән очракта) тарафыннан билгеләнгән каты коммуналь калдыклар туплау нормативлары кулланыла.»;

5.3.66 пунктта:

беренче абзацта «каты көнкүреш калдыклары өчен» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар өчен» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «калдыклар туплау нормалары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар туплау нормативлары» сүзләренә, «калдыклар туплау» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар өчен» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.72 пунктта «Каты һәм сыек көнкүреш калдыкларын зарарсызландыру» сүзләрен «Каты коммуналь һәм сыек көнкүреш калдыкларын зарарсызландыру» сүзләренә, «көнкүреш калдыкларын эшкәртү буенча» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар утильләштерү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.73 пунктта:

беренче абзацта «көнкүреш калдыкларын зарарсызландыру һәм эшкәртү буенча» сүзләрен «каты коммуналь калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча» сүзләренә алмаштырырга;

73 таблицада:

таблица исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«каты коммуналь калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча предприятиеләр һәм корылмаларның җир кишәрлекләре һәм санитария-саклау зоналары зурлыклары»;

«каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.74 пунктта «куллану калдыкларын транспортлау, зарарсызландыру, эшкәртү һәм күмү буенча» сүзләрен «куллану калдыкларын транспортлау, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча» сүзләренә алмаштырырга;

6.9 бүлектә:

6.9.2 пунктта «калдыкларны чыгару, эшкәртү һәм утильләштерү» сүзләрен «калдыкларны транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

6.9.3 пунктта «икенчел куллануны исәпкә алып, зарарсызландыру һәм эшкәртү» сүзләрен «утильләштерү һәм зарарсызландыру» сүзләренә алмаштырырга;

6.9.4 пунктта «эшкәртү, күмү урыннары» сүзләрен «утильләштерү, урнаштыру урыннары» сүзләренә, «калдыкларны эшкәртү (күмү) буенча» сүзләрен «калдыкларны утильләштерү, урнаштыру буенча» сүзләренә алмаштырырга;

6.9.6 пунктта «эшкәртү, термик зарарсызландыру, утильләштерү һәм күмү» сүзләрен «утильләштерү, термик зарарсызландыру һәм урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына 3 нче кушымтаның 2 таблицасындагы 8 пунктта «Көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү» сүзләрен «Каты коммуналь, сәнәгать һәм биология калдыкларын утильләштерү һәм урнаштыру» сүзләренә, «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков